ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ШАДЧИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Молодежная, д.18, с. Шадчи,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422145

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ШӘДЧЕ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
Яшьләр ур., 18 нче йорт, Шәдче авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422145

тел.(факс): (85563) 2-52-24; e-mail: Shad.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар | Постановление

20 февраль 2023 ел | № 35

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге башкарма комитетының 2014 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге халык дружинасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 55 нче номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Гражданнарның җәмәгать тәртибен саклауда катнашуы турында» 2014 елның 2 апрелендәге N 44-ФЗ Россия Федерациясе Федераль законына, «Җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (үзләштерүгә) каршы тору һәм террорчылыкны финанслау турында» Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 28 июнендәге № 219-ФЗ Федераль законына, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге башкарма комитетының 2014 елның 19 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Шәдче авыл җирлеге халык дружинасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 55 нче номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 3 бүлегендәге 1 пунктының 4 пунктчасына «яисә террорчылык оешмалары һәм террорчылар яки күпләп юк итү коралы таратуга катнашы булган оешмалар һәм физик затлар исемлегенә кертелгән, яисә БМО Уставының VII бүлеге, БМОның Куркынычсызлык Советы яисә БМО Куркынычсызлык советының махсус төзелгән карарлары белән каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында» сүзләрен өстәргә.

1.2. 1 нче кушымтаның 2 бүлегендәге 5 пунктының 4 пунктчасына «яисә террорчылык оешмалары һәм террорчылар яки күпләп юк итү коралы таратуга катнашы булган оешмалар һәм физик затлар исемлегенә кертелгән, яисә БМО

Уставының VII бүлеге, БМОның Куркынычсызлык Советы яисә БМО Куркынычсызлык советының махсус төзелгән карарлары белән каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында» сүзләрен өстәргә.;

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының (pravo.tatarstan.ru) рәсми порталында урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

3. Әлеге караның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгыма алам.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Шәдче авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе /В.В.Шрыков/